КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 22 гыйнвар г.Казань № 32

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 4 декабрь, 954 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 4 декабрь, 954 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 13 май, 317 нче; 2014 ел, 24 сентябрь, 670 нче; 2014 ел, 12 ноябрь, 861 нче; 2015 ел, 26 март, 189 нчы; 2016 ел, 2 декабрь, 889 нчы; 2018 ел, 28 май, 404 нче; 2018 ел, 10 сентябрь, 765 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, финанслау күләмнәре | Программаны финанслауның гомуми күләме 33 537 315,1 мең сум тәшкил итә, шул исәптән җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы исәбеннән – 266 582,0 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 2 428 917,7 мең сум, бюджеттан тыш чыганаклардан – 30 841 815,4 мең сум. |

(мең сум)

| Ел | Барлыгы | Татарстан Республикасы бюджеты | федераль бюджет | бюджеттан тыш чыганаклар |
|---|---|---|---|---|
| | | акчасы | | |
| 2014 | 4 813 302,2 | 1 273 412,8 | 266 582,0 | 3 273 307,4 |
| 2015 | 4 666 847,5 | 1 136 565,5 | 0,0 | 3 530 282,0 |
| 2016 | 3 891 326,0 | 0,0 | 0,0 | 3 891 326,0 |
| 2017 | 4 329 307,4 | 8 607,4 | 0,0 | 4 320 700,0 |
| 2018 | 4 760 635,4 | 4 735,4 | 0,0 | 4 755 900,0 |
| 2019 | 5 253 196,6 | 5 596,6 | 0,0 | 5 247 600,0 |
| 2020 | 5 822 700,0 | 0,0 | 0,0 | 5 822 700,0 |
| 2021 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |
| Барлыгы | 33 537 315,7 | 2 428 917,7 | 266 582,0 | 30 841 815,4 |

Программа юнәлешләре буенча Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган акча суммалары чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы нигезендә ел саен тәгаенләнәчәк.

Программаны федераль бюджет акчасы исәбеннән тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү күләме Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслашу шартларында Россия Федерациясенең Энергетика министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән ел саен төзелә торган килешүләр нигезендә билгеләнәчәк»;

Программаның III бүлегендә:

икенче абзацта «33 531 718,5» саннарын «33 537 315,7» саннарына алыштырырга;

тугызынчы абзацта «33 531 718,5» һәм «2 423 321,1» саннарын шул ук эзлеклелектә «33 537 315,7» һәм «2 428 917,7» саннарына алыштырырга;

Программа теркәлгән 1 нче кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин